**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы карары**

Бирючевка авылы №16 2023 елның "18" апреле

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2018 елның 04 маеннан №94 «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте ечен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте ечен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 04.10. № 107, 2018 елның 28.11. № 115, 2022 елның 24.10. № 48 карарлары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының, аудиторларының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2018 елның 04 маеннан №94 «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте ечен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә (2018 елның 04.10. № 107, 2018 елның 28.11. № 115, 2022 елның 24.10. № 48 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече теркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләменә тапкырлар исәпләнә, ул 12 688,00 сум тәшкил итә. »;

б) 2.2 пунктның икенче абзацта «7,71» санын «10,36» санына алмаштырырга, еченче абзацта «6,72» санын «9,26» санына алмаштырырга;

в) 3.2 пунктның 5 пунктчасында «1 процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3.3 пунктының 5 пунктчасында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

д) 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук

мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: З.Г.Солтанова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советы карарына
1 нче кушымта

18.04.2023. №16

Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының айлык акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исемнәре | Авыл җирлекләрендә | |
|---|---|---|
| | 11 теркем | 12 төркем |
| 1 | 2 | 3 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19 039 | 17 390 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 13 681 | 12 689 |
| Депутатлар | 12 688 | 12 688 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 12 688 | 12 688 |